ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» октябреннән № ____

2026 елда Татарстан Ресаубликасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында

Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, баланслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүнең һәм 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына гомуми башлангыч белем бирү мәгариф программалары буенча бер белем алучыга кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 726 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча белем алучыларны туклындыруны тәэмин итү бәясенә үзгәреш кертү турында» 2025 елның 03 октябрендәге 787 номерлы карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның кайнар туклануын оештыру турындагы нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучы статусына ия балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр түләүсез туклындыру бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 16 апрелендәге

100 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль Башкара комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучыларына уртача бәясе 77,76 сум булган кайнар аш белән тукландыру оештырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучыларына һәр уку көненә 10,70 сум күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага кайнар аш белән тукландыру оештырырга;

1.3. гаиләнең бер әгъзасына уртача җан башына кереме Татарстан Республикасы буенча билгеләнгән яшәү минимумыннан кимрәк булган һәм балигъ булмаган яшьтәге 4 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләнә торган күпбалалы гаиләләрдән булган укучылар өчен 77,76 сум бәясендә, шул исәптән субсидияләрне исәпкә алып, җирле бюджет акчалары исәбеннән түләүсез кайнар иртәнге аш оештырырга;

1.4. сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) укучыларны җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр бушлай ашатуны оештырырга:

1-4 сыйныфлары өчен бәясе 77,76 сумлык и 25 сумлык (озайтылган көн төркеме);

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 77,76 сумлык һәм 25 сумлык (озайтылган көн төркеме).

1.5. ата-аналары яки законлы вәкилләре махсус хәрби операциядә катнаша торган гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр бушлай ашатуны оештырырга:

1-4 сыйныфлары өчен бәясе 77,76 сумлык и 25 сумлык (озайтылган көн төркеме);

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 77,76 сумлык һәм 25 сумлык (озайтылган көн төркеме).

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына мәгариф учреждениеләре киселешендә аз керемле гаиләләрдән булган балаларны бушлай тукландыруны оештыру чыгымнарын Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауны башкарырга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә һәм укучыларны кайнар тукландыруны оештыручы башка оешмаларга:

3.1. мәктәп ашханәләрен туклануының сыйфатлы продуктлары белән өзлексез тәэмин итүне тәэмин итәргә;

3.2. витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләр балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итәргә;

3.3. гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм «гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПин 2.4.5.2409-08 нормативлары нигезендә, «Санитар кагыйдәләрне үтәү һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар үтәүгә производство контролен оештыру һәм үткәрү» СП 1.1.1058-01 номерлы СанПиН нигезендә производство контролен башкарырга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына түләүсез туклануны оештыру буенча социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм, билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы аша алынырга мөмкин.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 278 номерлы карары (2024 елның 27 ноябрендәге 297 номерлы, 2025 елның 25 февралендәге 48 номерлы, 2025 елның 21 июлендәге 160 номерлы, 2025 елның 13 августындагы 173 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) түз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Фасахов